# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 29 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 94 (часть I) следующие изменения:

1) пункт $15^{1}$ статьи 11 изложить в следующей редакции:

«$15^{1}$) утверждение положения о региональном государственном контроле (надзоре) на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве;»;

2) в пункте 1 статьи 12 слова «надзора за обеспечением сохранности автомобильных дорог регионального значения» заменить словами «контроля (надзора) на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве»;

3) в статье 13:

а) пункт $1^{1}$ изложить в следующей редакции:

«$1^{1}$) утверждение положения о муниципальном контроле на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве;»;

б) в пункте 2 слова «за обеспечением сохранности автомобильных дорог местного значения» заменить словами «на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве»;

4) статью $13^1$ изложить в следующей редакции:

«Статья $13^1$. **Региональный государственный контроль (надзор), муниципальный контроль на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве**

1. Региональный государственный контроль (надзор), муниципальный контроль на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве за соблюдением обязательных требований, установленных федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, законами и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, муниципальными нормативными правовыми актами, международными договорами Российской Федерации, актами, составляющими право Евразийского экономического союза, в сфере автомобильного транспорта и городского наземного электрического транспорта, автомобильных дорог, дорожной деятельности в части сохранности автомобильных дорог, осуществляется соответственно:

1) уполномоченным органом в соответствии с положением, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан;

2) уполномоченными органами местного самоуправления в соответствии с положениями, утверждаемыми представительными органами муниципальных образований.

2. Полномочия по осуществлению регионального государственного контроля (надзора), муниципального контроля на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве или отдельные полномочия по их осуществлению решением Кабинета Министров Республики Татарстан, решением главы местной администрации могут быть возложены на государственные, муниципальные учреждения.

3. В случае возложения полномочий по осуществлению регионального государственного контроля (надзора), муниципального контроля на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве или отдельных полномочий по их осуществлению на государственные, муниципальные учреждения в соответствии с частью 2 настоящей статьи, принятие нормативных правовых актов, отнесенных Федеральным законом от 31 июля 2020 года № 248-ФЗ «О государственном контроле (надзоре) и муниципальном контроле в Российской Федерации» к полномочиям контрольных (надзорных) органов, осуществляется уполномоченным органом, уполномоченным органом местного самоуправления.

4. Предметом регионального государственного контроля (надзора) на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве является соблюдение обязательных требований в области автомобильных дорог и дорожной деятельности, установленных в отношении автомобильных дорог регионального значения:

1) к эксплуатации объектов дорожного сервиса, размещенных в полосах отвода и (или) придорожных полосах автомобильных дорог общего пользования;

2) к осуществлению работ по капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования и искусственных дорожных сооружений на них (включая требования к дорожно-строительным материалам и изделиям) в части обеспечения сохранности автомобильных дорог.

5. Предметом муниципального контроля на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве является соблюдение обязательных требований:

1) в области автомобильных дорог и дорожной деятельности, установленных в отношении автомобильных дорог местного значения:

а) к эксплуатации объектов дорожного сервиса, размещенных в полосах отвода и (или) придорожных полосах автомобильных дорог общего пользования;

б) к осуществлению работ по капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования и искусственных дорожных сооружений на них (включая требования к дорожно-строительным материалам и изделиям) в части обеспечения сохранности автомобильных дорог;

2) установленных в отношении перевозок по муниципальным маршрутам регулярных перевозок, не относящихся к предмету федерального государственного контроля (надзора) на автомобильном транспорте, городском наземном электрическом транспорте и в дорожном хозяйстве в области организации регулярных перевозок.».

**Статья 2**

Внести в статью 5 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 77-ЗРТ «О перевозках пассажиров и багажа легковыми такси на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть); 2012, № 7 (I часть) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«Статья 5. **Региональный государственный контроль (надзор) в сфере перевозок пассажиров и багажа легковым такси**

1. Региональный государственный контроль (надзор) в сфере перевозок пассажиров и багажа легковым такси осуществляется уполномоченным органом в соответствии с положением, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Предметом регионального государственного контроля (надзора) в сфере перевозок пассажиров и багажа легковым такси является соблюдение организациями и индивидуальными предпринимателями, осуществляющими деятельность по оказанию услуг по перевозке пассажиров и багажа легковым такси, обязательных требований, установленных статьей 9 Федерального закона и правилами перевозок пассажиров и багажа легковым такси, а также требований к

обеспечению доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых услуг.».

**Статья 3**

Внести в статью 4 Закона Республики Татарстан от 20 декабря 2018 года № 103-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в области организации дорожного движения в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I); 2020, № 51 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 3 части 1 признать утратившим силу;

2) пункт 6 части 2 изложить в следующей редакции:

«6) осуществление государственного контроля (надзора) за реализацией органами исполнительной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления полномочий в области организации дорожного движения;».

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
04 октября 2021 года
№ 75-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

### 1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның $15^{1}$ пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$15^{1}$) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау;»;

2) 12 статьяның 1 пунктында «Региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өчен региональ дәүләт күзәтчелеген» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяда:

а) $1^{1}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^{1}$) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау;»;

б) 2 пунктта «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алмаштырырга;

4) $13^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$13^1$ статья. **Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), муниципаль контроль**

1. Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, автомобиль юллары, юл хуҗалыгы өлкәсендә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Евразия икътисадый союзы хокукын тәшкил итүче актларда автомобиль юллары сакланышы өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), муниципаль контроль түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, вәкаләтле орган;

2) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан раслана торган нигезләмәләргә таянып, җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары.

2. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре яисә аларны башкару буенча аерым вәкаләтләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, җирле администрация башлыгы карары белән дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә йөкләнергә мөмкин.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре яисә аларны башкару буенча аерым вәкаләтләр дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә йөкләнгән очракта, «Россия Федерациясендә дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән тикшереп тору (күзәтчелек итү) органнары вәкаләтләренә кертелгән норматив хокукый актларны кабул итү вәкаләтле орган, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметы автомобиль юллары һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлларына карата билгеләнгән түбәндәге мәҗбүри таләпләрне үтәүдән гыйбарәт:

1) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосаларында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә карата;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын

капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм аларны карап тоту эшләрен башкаруга карата (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә карата таләпләрне дә кертеп).

5. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль предметы түбәндәге мәҗбүри таләпләрне үтәүдән гыйбарәт:

1) автомобиль юллары һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата билгеләнгән түбәндәге мондый таләпләр:

а) гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосаларында һәм (яисә) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләүгә карата;

б) автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү өлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма юл корылмаларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм аларны карап тоту эшләрен башкаруга карата (юл-төзелеш материалларына һәм эшләнмәләренә карата таләпләрне дә кертеп);

2) даими ташуларны оештыру өлкәсендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында федераль дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметына карамаган даими ташуларны муниципаль маршрутлар буенча ташуларга карата.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5 статья. **Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге)**

1. Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт тикшереп торуы (күзәтчелеге) предметы җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәтләрен күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан Федераль законның 9 статьясында һәм җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, шулай ук инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктураларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәүдән гыйбарәт.».

**3 статья**

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге вәкаләтләрне башкаруны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру;».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 75-ТРЗ